# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 24.11.2024 ел

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 3500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (Җәлил урамына вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Каменка торак пункты территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин